СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 5-2 от « 26 » октября 2020 г.

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлдән чыгару турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 26.3 бүлеге гамәлдән чыгуга бәйле рәвештә, 2012 нче елның 29 июнендәге «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 26 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» №97-ФЗ Федераль закон нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елның 12 ноябрендә кабул ителгән 6-12 номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның хокукый акт текстын «Нократ» («Вятка») район газетасында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://mamadysh.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru ) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының бюджет, икътисадый сәясәт һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

000091